وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№2 (119). 13 гыйнвар 2012 / 19-сафәр-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Шәҗәрә төзү - асылыбызга кайту ▷ 2 ◁





"Тәварихе Болгария" әсәрен кем язган? ▷3◁





Мәрхәмәтле булыйк! ▷4◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

### БӘРӘКӘТЛЕ КАНИКУЛ

Бөгелмә шәһәренең Җәмигъ мәчете каршында мөселман балалары өчен оештырылган кышкы лагерь үз эшен тәмамлады.

Бөгелмә мөхтәсибәтенең дәгъват кылу һәм мәгълүмат бирү бүлеге биргән хәбәрләргә караганда, алты көн дәвамында мәчеттә кырыктан артык бала белем алган. Бу вакыт эчендә алар Коръән сүрәләре өйрәнгән, догалар ятлаган. Моннан тыш, алар өчен кышкы уеннар оештырылган. Балалар янына очрашуга ЮХИДИ хезмәткәрләре дә чакырылган булган.

***Чыганак: www.dumrt.ru***

### НАМАЗ УКУ БӘЙГЕСЕ ҮТКӘРЕЛДЕ

8 гыйнвар көнне Татарстанның Тукай районында намаз уку бәйгесе узды. Бәйге районның Теләнче Тамак авылында урнашкан мәчеттә (ул мәгърифәтче Хәлфиннар тарафыннан төзелгән) оештырылды.

Кызлар һәм малайлар арасында уздырылган бәйге вакытында жюри әгъзалары намаздагы хәрәкәтләрнең дөреслегенә, Коръән сүрәләренең дөрес укылышына игътибар иткән.

Чара тәмамлану белән, мәҗлес корылып, вәгазьләр тыңланган, имамнар бәйгедә катнашучыларның сорауларына җавап биргән.

Исегезгә төшерәбез: Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, 2011 елның 27 сентябрендә РИУда узган мәчет каршында дини белем бирүче мөгаллимнәрнең республика киңәшмәсендә мондый төрдәге бәйгеләр уздыру тәкъдиме белән чыккан иде.

***Чыганак: www.muslem.ru***

### ЯШЕЛ ҮЗӘНДӘ ДӘ БАЛАЛАР ЯЛ ИТТЕ

1-10 гыйнвар көннәрендә Яшел үзән мөхтәсибәте үзләренең башлангыч мәдрәсә бинасында балалар өчен кышкы лагерь оештырды. Бирәдәге лагерь шунысы белән дә үзенчәлекле: монда мәктәпкәчә яшьтәге балалар да бар иде.

Унике яшькә кадәрге балалар лагерьда иртәнге тугыздан алып 15.30 сәгатькә кадәр ял иткән, гыйлем алган. "Төп максат итеп балаларга тәрбия дәресләре бирүне куйдык, Коръән, җәмәгать намазлары уку әдәпләренә дә төшендердек. Балалар өчен хәрәкәтле уеннар, туристик базада чаңгыда шуулар да үткәрдек. Мөселман кинолары күрсәттек. Конкурс-бәйгеләр оештырдык", - дип белдерде "Дин вә мәгыйшәт" газетасы хәбәрчесенә Яшел үзән шәһәре һәм Яшел үзән районы имам-мөхтәсибе Габделхәмит хәзрәт Зиннәтуллин.

Аш-су осталары балалар өчен көненә өч тапкыр өстәл әзерләгән.

**P.R.: күптән түгел генә Яшел үзән мөхтәсибәте картлар йортларында тәрбияләнүчеләр белән дә очрашулар үткәргән.**


### КОТЛЫЙБЫЗ!

Бүген, ягъни 13 гыйнвар көнне илебездә Россия матбугаты көне билгеләп үтелә. Чөнки нәкъ менә шул көнне Пётр I указы белән Россиядә беренче "Ведомости" газетасы дөнья күргән.

Без барлык хәбәрчеләребезне дә ТР мөселманнары Диния нәзарәте исеменнән шушы истәлекле көн белән тәбрик итәбез, исәнлек-саулык һәм зурдан-зур иҗат уңышлары телибез. Хәбәрчеләребезгә килгәндә исә, аларның иң актив-өлгерләре Балтач, Кукмара, Мамадыш районнарында һәм Бөгелмә, Чаллы шәһәрләрендә яши. Аларга үзебезнең киң рәхмәтебезне җиткерәбез һәм алга таба да бергәләшеп өммәтебезгә хезмәт итәрбез, дигән теләктә калабыз.

## БИСМИЛЛӘҺ!

**"Бисмилләһ" - "Аллаһы Тәгалә хакына" дигәнне аңлата. Бу сүзләр белән мөселман кешесе һәр эшен башлый. Ислам дине турында белемнәре сай булган кешеләр бу сүзләр бары тик дин әһелләре тарафыннан вәгазь сөйләр алдыннан гына әйтелә торгандыр дип уйлый (гәрчә алар аны үзләре йокыга китәр алдыннан, сүзләрнең тирән мәгънәсенә төшенмичә әйтсәләр дә). "Бисмилләһ" сүзе турында уйлана башласак, безгә ислам диненең төп асылы - Аллаһы Тәгалә белән бәйләнеш ачылачак. Моның асылы нәрсәдә соң?**



"Аллаһы Тәгалә хакына" яки "Аллаһы Тәгаләнең исеме белән". Гарәп телендә исә христианнар, мөселманнар яки башка берәр дингә тотучылар үзләре табынган бердәнбер Илаһи көчне "Аллаһ" дип атый. Аллаһ - дөньяны барлыкка китерүче бердәнбер Илаһи көч. Мөселманнар бу турыда онытырга тиеш түгел. Дөньядагы һәрбер кешене Аллаһы Тәгалә яраткан һәм дөньяга китергән, димәк, Аллаһы Тәгалә тудырган һәрбер зат мөселманнар тарафыннан ихтирамга лаек.

Аллаһы Тәгалә исеме белән, Аңа ышанып, без эшләребезне башлыйбыз. Без җаваплылыкны Аңа кайтарып калдырмыйбыз, киресенчә, ислам динен сайлап, эшләребезне мөселманнарга тиеш булганча башкаруны үзебезгә бурыч итеп куябыз.

Тормышта һәрвакытта да уйлап эш итү мөһим. Гадәти эшләрне башкарганда уйлап эш итү читенрәк. Без, гадәтләнгәнчә, "бисмилләһ" дибез икән, димәк, бу сүзләр белән өстебезгә алынган җаваплылык турында онытабыз. Бу сүзләр Аллаһы Тәгалә каршында эчкерсез булырга бирелгән ант кебек. Һәм бу - дөньяда да, ахирәттә дә уңышка китерә. Сүзләр изге була алмый, аларны аңлау һәм изгелек хисен тою гына безне уңышлы итә алачак. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: "Ий сез мөэминнәр, антыгызны бозып, бөтен көчен куеп йоннан эрләгән яхшы җепләрен сүтеп, өзгәләп яраксыз иткән юләр хатын кебек булмагыз! Сез үзара хәйлә өчен ант итсәгез, әгәр үзегез башкалардан аз булсагыз, "сугышмыйбыз" дип ант итсәгез, күбәйсәгез, шул антыгызны бозып сугыша башлыйсыз. Тәхкыйк, Аллаһ сезне ант итүләрегез белән сыныйдыр. Аллаһ хөкемнәренә хилаф эшләрегезне Кыямәт көнендә, әлбәттә, Аллаһ, үзегезгә белдерер һәм хөкем итәр" ("Нәхел (Умарта кортлары)" сүрәсе, 92 нче аять).

Һәрбер әйтелгән сүзне, ниятне аңлау һәм алар өчен җаваплылык хисен сизү генә мөселман кешесен бизи. Бу турыда Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә пәйгамбәребез Мөхәммәт (гсв) сүзләре белән болай ди: "Син аларга әйт: "Әгәр Аллаһ кушмаса вә теләмәсә, мин сезгә Коръәнне укымас идем һәм аның хөкемнәрен сезгә өйрәтмәс идем. Тәхкыйк, пәйгамбәр булганчы, мин сезнең арагызда кырык ел тордым. Аллаһ кушмагач, ул дәвердә мин сезгә һичнәрсә укымадым, шуны фикерләп карамыйсызмы?" ("Юныс" сүрәсе, 16 нчы аять).

Билгеле булганча, пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв), аңа Коръән иңдерелгәнче үк, Бердәнбер Аллаһка табынган. Ул башкалардан үзенең кешелеклелек сыйфатлары белән аерылып торган. Эчкерсезлек, үз сүзләрең өчен җаваплылык, ваемсыз булмау кебек сыйфатлар барыбызга да кешеләр арасында танылуга, шул исәптән, уңышларга ирешүгә китерер. Ә ул уңышларның иң зурысы - ахирәттә. Әмин.

**Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

## "Гаилә бәхетеннән мәхрүм итүчеләр"

**10 гыйнвар көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтенә Түбән Кама шәһәрендәге "Рисалә" мәдрәсәсенең хәзерге директоры Рафикъ хәзрәт Исламгалиев белән шул ук шәһәрдә яшәүче Илдус Зартдинов килде.**

Әлеге ике шәхесне нинди мәсьәлә берләштерә дә, нинди проблема аларны Казанга алып килгән, диярсез. Эш бик тә җитди булып чыкты. Түбән Кама "дин әһелләре"-нең бернинди мәзһәбсез яшәргә чакыруы, аларның "чиста ислам" гакыйдәсен Такытдин Ибне Таймия (1263-1328), Габделгазиз Ибне Баз (1912-1999) фәтваларына нигезләнеп пропагандалавы, динне милли гореф-гадәт, традицияләрдән азат күреп, республикабыз җирлегенә ислам диненең Согуд Гарәбстанындагы вариантын күчереп утыртырга тырышу "җимешләре"н, беренчеләрдән булып, Илдус Зартдинов үз гаиләсе мисалында татый. Аның кияве - "Рисалә" мәдрәсәсен тәмамлап, аннан соң шушы ук мәдрәсәнең кичке бүлегендә "укытучы" булып эшли башлаган егет - әлеге гаилә башлыгын сөйгән хатыныннан, үз улыннан аерган. Сәбәбе нидә, дисезме? Имештер, аның гакыйдәсе дөрес түгел. Эш шуңа барып җиткән ки, кияү кеше хәтта Илдусның хатыны Фәридәне, шушы "кяфер" ирдән аерылу өчен судка гариза язу эшенә дә котырткан. Һәм теге зомбилашкан хатын




ундүрт ел бергә гомер кичергән ире белән аерылу өчен судка гариза биргән. Алар хәзерге вакытта да бер-берләрен үлеп яратуларына карамастан, 27 гыйнвар көнне гаилә рәсми рәвештә судлашып аерылышырга тиеш. Фәридә исә бүгенге көндә: "Мин синнән башка яши алмыйм", - дип иренә SMS-хәбәрләр язуын дәвам иттерә...

Әйе, менә инде айга якын Фәридә сәләфиләр "тоткынлыгы"-нда яши. Кияве Илдар Җиһаншин, хәнәфи мәзһәбендә гомер кичергән Илдусны ялгыз гына калдырып, кеше хатынын да үзенең дини карашларына күндерергә маташып, аны да "урлап" алып чыгып китә...

Безнең татарда, традиция буенча, егет кеше үз әти-әнисе белән яисә башка чыгып аерым яши. Беренче көннән үк ислам динендә, хәнәфи мәзһәбе, матуриди гакыйдәсенә тугры калган гаилә башлыгы Илдус Зартдиновка бу сәләфи егет каян, ничек, ни сәбәпле килеп эләккән дә, кеше гаиләсен пыран-заран китерү нилектән башланган дисезме?


*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# "Гаилә бәхетеннән мәхрүм итүчеләр"

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Менә хәзер шуларны бәйнә-бәйнә язып үтәрбез. Мондый хәл, минем карашка, бәлки килеп тә тумаган булыр иде. Тик аның кеше гаиләсе таркалу белән генә түгел, моннан да коточкычрак хәлләр - кеше канын коюларга, шартлау-шартлату кебек афәтләргә дә алып китереп җиткезүе бик мөмкин. Безнең очракта исә хатынның иренә тиктомалдан "хыянәт итүе" ни рәвешле башлана соң? Кияүнең "хыялы" тормышка ашу процессын тагын да җиңеләйтә төшүче сәбәпләр күзгә ярылып ята. Беренчедән, ничек кенә булмасын, кияү белән кыз Мәдинәгә укырга китәр алдыннан үз фатирларын бүтән кешегә яшәргә тапшыра. Без булмаганда буш тормасын, "исраф булмасын", аз гына булса да акча китерсен, янәсе. Алар үзләре Илдус Зартдиновларга яшәргә кереп тора. Мәдинәгә киткәнче, "өч-дүрт ай вакыт"ка гына дип. Менә шул "өч-дүрт ай вакыт" эчендә буласы хәлләр була да инде. (Шунысын да искәртеп узыйк: мондагы фатирда яши башлаганнар хәзер кайсысы нинди дини белемгә, мәзһәбкә, гакыйдәгә ия булмасын - аларның һәммәсе дә намаз укый. Аек акыл белән уйлап караганда, беркемне дә "кяфер" дип атап булмас шикелле, чөнки, кабатлап әйтәм, барчасы да намаз укый бит!) Ягъни, ике бүлмәле фатирда яшәүчеләрнең дөньялыкта була торган борчу, тормыш мәшәкатьләреннән бигрәк, дини мәсьәләләрне хәл итү "проблемалар"ы барыннан да өстен чыга. Биредә катализатор, икенче төрле әйткәндә, киеренкелекне тагын да көчәйтүче булып, матуриди гакыйдәсе буенча чыгарылган Рәшит Исаевның "Гакыйдә" дискы килеп керә. Кичләрен, буш вакытларда фатир хуҗасы - Илдус Зартдинов менә шул дискны кабызып куя торган була. Менә шушы диск "Рисалә" мәдрәсәсен тәмамлаган кияүнең йөз сиксән градуска үзгәрүенә сәбәп була да инде. Ул аны бик нык ярсыта...

Илдус Зартдинов - бик тә гади, самими, эчкерсез кеше. Эчендәгесе тышында, күңелендәгесен әйтеп бирә. Гадәти эштә эшли. Казанга да төнге сменадан кайткан килеш чыгып киткән. Һөнәре, кәсебе турында төпченеп сорамадык. Аның: "Ике бүлмәле фатирыбыз бар. Йөрергә җиңел машинабыз, бакчабыз, хәләл кәсеп итәргә йөк машинабыз да бар. Ашау-эчү, кием-салым, йорт җиһазлары - һәммәсе дә җитәрлек", - дигән җавабы гаиләнең житеш тормышта яшәгәнлегенә дәлил булып тора иде.

Ул, 1985 елда армиядән кайткач, әнисе белән Чүпрәле районыннан Ульяновск шәһәренә күчеп килә. Совет чорында ук аның дини хисләрен уятып җибәрергә, намазга басарга дусты - Тәтеш районының Кече Тархан авылында яшьтән үк дини гыйлем алып үскән Вәгыйзь абый сәбәпче була. Шулай итеп, ул Ульяновск өлкәсе мәхәлләләренә намазга йөри башлый. Соңрак, 1986 елларда Самара өлкәсендә гомер кичергән Габделәхәт хәзрәт Минһаҗев белән танышып, аңардан хәнәфи мәзһәбе буенча дини гыйлем ала. 1993 елда Илдус Зартдинов әнисе белән Татарстанга - Түбән Кама шәһәренә күченеп кайта. "Шәһәр миңа үзенең яшеллеге, манаралары белән күккә ашып төзелеп килүче хәзерге Җәмигъ мәчете белән беренче карашка бик тә ошаган иде", - дип искә ала ул. Ничек кенә әле! Шушы елны аның әнисе дә намазга баса, ул исә биредә шәһәр әбиләре белән дини белемнәр алып, үз өстендә эшли. Илдус әфәнде дә җае чыккан саен ул вакыттагы "Кызыл чишмә" мәчете имамы Әдип хәзрәт Вәлиев белән танышып, дуслашып, хәнәфи мәзһәбе буенча дини белемнәрен тагын да тирәнәйтә. Шул гомердән бирле - ике дистә елдан артык И.Зартдинов хәнәфи мәзһәбенә тугры булып кала бирә. Ул 2008 елда хатыны Фәридә белән хаҗ кылып кайта. Алар шулай бер-берсенә терәк булып яши бирәләр. Илдус әфәнденең хәләл җефете 2010 елда авырып, III группа инвалидлыкка чыга. Шул чакта да аны Илдус Зартдинов больницаларда күтәреп кенә йөри, бер ел дәвамында урын өстендә яткан хатынын тәрбия кыла.

2011 ел урталарында "Рисалә" мәдрәсәсенә директор итеп аның дини карашларына туры килгән мәзһәб, гакыйдәдә булган Рафикъ хәзрәт Исламгалиев билгеләнүне дә бик шатланып кабул итә ул. Бүтән дин-кардәшләре кебек үк И.Зартдинов та "яңа" хәзрәткә үгет-нәсыйхәтләр, киңәшләр алырга йөри башлый. Рафикъ Исламгалиев исә бер генә кешене дә кире какмый, мәзһәб, гакыйдә буенча килеп туган сорауларның һәммәсенә дә итагатьле итеп җавап кайтара. Алай гына да түгел, теләгән кешегә Татарстан Диния нәзарәте рөхсәт иткән китапларны, аудио-дискларны да биреп чыгара. Мисал өчен, узган көз мөфтият Рәшит Исаевның "Гакыйдә" дискын чыгарган иде. Шушы дискны Илдус Зартдинов та сорап ала. Нияте - аны өенә алып кайтып тыңлау...

Менә шуннан башлана да инде. Вакыты да туры килеп тора бит - каян ул вакытта аның кияве хатыны белән яшәргә килгән диген! Гакыйдә мәсьәләләре турысында өйдә зур тавыш-гауга чыга.

- Әлбәттә, ике гаиләнең (минем 13 яшьлек малаем да бар) ике бүлмәле фатирда яшәве авырлыклар тудыра башлады. Мин, ата кеше буларак, ир хакларын үтәр өчен билгеле бер кыенлыклар сизә башладым. Кияү белән кызга: "Әниегезнең дүрт бүлмәле фатирына барып торыгыз", - дигәч, риза булмыйча тавыш чыгардылар. Икесе дә Түбән Кама Җәмигъ мәчетенең кичке бүлек укытучылары була торып, "Рәхмәт, өч ай тоттыгыз" диясе урынга, кияү кеше әдәпсез рәвештә: "Аллах тебя накажет", - дип чыгып китте. Нәрсә өчен икәнен аңламадым. Икенче көнне кияү белән кыз килеп: "Синең гакыйдәң дөрес түгел! Синең Коръәнне кулыңа тотып укырга хакың юк! Ничтожество, нәҗес син! Син хатыныңа не достоен! Сиңа аның белән яшәү хәрам", - дип, ир кеше талак әйтмәстән, өемнән хатыным белән малаемны миннән кыргыйларча "аерып" алып чыгып китеп, съёмный фатирга яшереп куйдылар. Хәзер 2011 елның 15 декабреннән бирле хатыным белән улым Исмәгыйльне күргәнем юк. Кайда торалар - Аллаһ белә, адресларын да белгертмиләр, - дип сөйләде Илдус Зартдинов. (Аның хатыны үз "гаебен танып" 6 гыйнвар көнне генә кайта.)

Шушы вакыйгаларның икенче көнендә Илдус әфәнде бу хәлләрне Түбән Кама Җәмигъ мәчетенә барып, Габделкәрим хәзрәткә сөйләп бирә, Ирек хәзрәткә керә. Тик нәтиҗәсез, рус әйтмешли, ноль внимания. Габделкәрим хәзрәт: "Аллаһ ярдәмен бирсен!" - дию белән чикләнсә, Ирек хәзрәт Мөниев: "Мәдрәсәдә укып чыгучыларның җинаяте өчен җавап бирмибез", - дип әйтеп котыла. Аптырагач, Илдус Зартдинов Түбән Кама мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшин янына керә. Тик анысы да кымшанмый. Мин аңа: "Кияүне, кызны, хатынны, үземне берьюлы чакырып, аңлат! Нинди гакыйдәгә таянып, сездә укып чыккан шәкертнең ир белән хатынны аерырга хакы бар?" - дип әйткәч тә, исе китмәде: "Ярар", - дип кенә калды. Габделкәрим хәзрәткә дүртенче баруымда: "Әгәр дә минем гаиләм хакына безне җыеп аңлатмасагыз, Казанга - мөфтияткә барам, дигәч тә исләре китмәде. Чөнки алар - Түбән Кама мәчетендәге барлык хәзрәтләр дә - шәригатьтә "крайность"ка сикергән укытучыларының бозык гамәлләрен яшерергә тырышты. Йөрер-йөрер дә, туктар әле, диделәр. Синең гаиләң таркалсын, балаң ятим калсын - боларның берсенә дә аларның исе китми - бары тик дәрәҗәләре һәм урыннары гына югалмасын", - дип аңлатма бирде бу хәлләрдән җәфа чигүче Илдус Зартдинов.

Шунысы кызганыч, Түбән Кама мөхтәсибе мондый мәсьәләләр иң әүвәл төбәк казые белән хәл ителергә тиешлеген башына да китерми. Үзе аңлатмалар бирүдән баш тарта икән, хет аларны казыйга җибәрсен, хет казыйның телефон номерын бирсен иде инде. Боларның берсе дә эшләнми. Без исә, үз чиратыбызда, дүртенче хакимият вәкиле буларак, журналистка бирелгән хокукларыбызны эшкә җигеп, Түбән Кама мәдрәсәсенең хәзерге директоры Рафикъ хәзрәт Исламгалиевтән аңлатмалар алырга булдык.

**Рафикъ хәзрәт Исламгалиев, "Рисалә" мәдрәсәсе директоры:**

- Безнең шәригатебездә хатын-кыз үз теләге белән генә иреннән аерыла алмый. Чөнки өйләнгәндә ир-ат үз өстенә зур күләмле йөкләмәләр ала: ул хатынын йорт-җир, ашау-эчү, кием-салым һәм көндәлек чыгымнар белән тәэмин итәргә тиеш була. Болар үтәлмәсә яки ир-ат үти алмаса, аның өйләнүе - золым кылу була. Хатын-кыз талак-аерылу өчен казыйга бары тик шундый очракларда - әгәр дә ир-ат үзенең хатынын тиешенчә тәэмин итә алмаса яисә нәселсез (импотент) булса гына турыдан-туры мөрәҗәгать итә ала. Әгәр дә ир-ат кеше өеннән командировкага чыгып китәргә җыенса, ул әҗәткә акча алып булса да, гаиләсен тәэмин итәрлек мал-мөлкәт калдырырга тиеш. Әгәр дә ул хатын-кызга җитәрлек акча, мал-мөлкәт калдырмаса (яки ул калдырган акча, мал-мөлкәт яшәр өчен җитәрлек булмаса), бу очракта аның хатыны казыйга дәгъва белән бара ала. Безнең мисалда исә Илдус Зартдиновның сәламәтлеге яхшы, ул гаиләсен тәэмин итәрлек хәлдә, аның тормышы бар яктан да җитеш. Бу очракта аны кяферлеккә чыгарып, аның хатынын аерып алып китү (талакка чыгару) дөрес булмый. Хатыны аннан риза булмаган очракта да, ул төбәк казыена - Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиевкә мөрәҗәгать итәргә тиеш иде. Теләсә кемнең үзеннән фәтва чыгарып, кеше гаиләләренең оясын туздырып, аларны аерып, балаларны ятим итеп йөрергә хакы юк. Безнең очракта Түбән Кама районы мөхтәсибенә Илдус әфәнде күп тапкырлар мөрәҗәгать итеп тә, бу мәсьәләләргә Йосыф Дәүләтшинның күз йомып килүе - аны мөхтәсиб буларак, бер дә бизәми. Мондый сыйфатлар (бигрәк тә кеше гаиләләренең язмышларын хәл иткәндә) - дин әһелләренә хас сыйфатлар түгел. Һәм бу аның үз эшенә салкын каравын күрсәтә.

**Нияз САБИРҖАНОВ**

## Мостафа Габделҗәлил гражданнар сугышына каршы



**Соңгы бәрелешләрдән соң ук, Ливиянең Вакытлыча күчеш советы башлыгы Мостафа Габделҗәлил үзенең мөрәҗәгатен җиткерде. "Халык гражданнар сугышына тартылырга мөмкин", - дип кисәтте ул.**

Мостафа Габделҗәлил үзен борчыган мәсьәләләрне болайрак аңлатты: "Мин ливиялеләрне гражданнар сугышыннан кисәтәм".

Вакытлыча күчеш советы башлыгының чыгышы Вакытлыча советның халыкара көчләре һәм Мисратның баш күтәрүчеләр группировкаларының берсе арасында булган бәрелешләрдән соң ук яңгырады.

Бәрелешнең үзе турында каршылыклы мәгълүматлар бирелә. Бәрелешләр вакытында алты кеше үлгән һәм ундүрте яраланган, дип хәбәр ителә. М.Габделҗәлил сүзләренә караганда, бәрелешләр бер төркем коралланган кешеләрнең әз-Зәвия районындагы бер хастаханәне басып алганнан һәм үз вазифаларын үтәүче табибны тышка чыгарырга маташканнан соң башлана.

Бәрелешләр, хәрбиләр коралларын Трипольнең разведка бинасына юнәлткәннән һәм Мисратның баш күтәрүчеләрен аны ташлап китүләрен таләп иткәннән соң башланды, дип, аңа хәтле эфирга чыккан репортажда хәбәр ителгән булган. Бәрелеш барышында җиңелчә һәм уртача зыян китерә торган корал кулланылган.

Кабиләләр бәрелеше шәехләр катнашы белән туктатылганнан соң, Трипольдә чагыштырмача тынычлык урнашты.

Каддафи режимы "вафат булган"нан бирле, Ливия башкаласында һәм шулай ук илнең башка шәһәрләрендә дә вакыты-вакыты белән бәрелешләр булып ала.

*Әхмәт ЙЫЛМАЗ*
*Русчадан татарчага Ландыш ҖИҺАНШИНА тәрҗемәсе*
*Чыганак: www.islam-portal.ru*

## Шәҗәрә төзү - асылыбызга кайту

***Соңгы арада нәсел шәҗәрәсен төзү кебек күркәм гадәт модага әйләнде. Тукай, Әмирхан, Мәрҗани кебек бөек шәхесләрнең нәсел агачлары белән бергә хәзерге вакытта М.Шәймиев, Р.Миңнеханов, И.Халиков та үз бабалары тарихын барлый.***



Татар халкына җиде буын бабаны белергә кушылган. Бу - юкка түгел, галимнәр кешенең генетик хәтере җиде буынга кадәр сакланганын раслаган. Кан да җиде буын саен яңара.

Халкыбызда ата-аналар балаларын нәселен яхшы белгән кешеләргә бирергә тырышкан. Бу - аларны төрле буыннан-буынга килә торган чирләрдән саклаган. Моннан тыш, җиде буын - кан хәтере генә түгел, акыл хәтере дә. Бүгенге көндә галимнәр зирәклелек, төрле сәләтләрнең дә буыннар буенча баруын раслады. Шуңа күрә мулла-мөәззиннәр нәселе, табиблар, галимнәр нәселе дип сөйлибез.

Соңгы араларда халык ни өчен үз нәселен өйрәнергә тотынды соң? Заманында зыялылар аны төзеп барган. Бүген Ф.Әмирхан, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри кебек нәсел язмалары - галимнәр өчен әзер чыганак. Совет чорында, киресенчә, ата-бабаның кем икәнен онытырга тырышканнар. Чөнки "мулла кызы", "кулак баласы" булу кешене гомере буена кара күләгә булып озата йөргән.

ТР Милли музееның бер хезмәткәре белән кешеләрнең күпләп шәҗәрә ясавы турында сөйләштек. Әлеге ханым нәсел буыннарын барлау күркәм күренеш дип санаса да, кешеләрнең аны мода итүенә, әхлакый кыйммәтен онытуына борчылуын белдерде. Музей хезмәткәрләренә буыннарны барларга заказ биреп, соңыннан бабалары гади кешеләр булуы ачыклангач, шау-шу куптарып, талашып китүчеләр дә аз түгел икән.

### НӘСЕЛЕН ӨЙРӘНҮЧЕГӘ ИШЕКЛӘР АЧЫК

Татарстан Республикасы Милли архивының баш белгече Лалә Хәсәншина сүзләренә караганда, архивта утыручыларның өчтән бере биредә нәсел-ыруын өйрәнә. Калганнары - я галимнәр, я студентлар. АКШ, Япония, Алманиядән дә килеп шөгыльләнәләр, чөнки фонд шактый бай, документлар да яхшы сакланган.

Тамырлары Татарстаннан чыккан кешене кызыктырырлык чыганаклар да күп монда. Архивта XVIII-XIX гасырга караган ревизия (халык саны алу) документлары, метрика кенәгәләре, хуҗалык карталары һәм башка әһәмиятле язмалар саклана.

Авыл мәхәлләләрендә кешеләрнең туган, вафат булган, өйләнешкән, аерылышкан вакытлары ел саен метрика кенәгәсенә кертелгән. Милли архивта 1829-1920 елгы метрика документлары бар. Ләкин алар гарәп графикасында язылганга, аларны бар кеше дә укый алмый. Бу очракта, Л.Хәсәншина сүзләренә караганда, махсус хезмәткәрләр ярдәм итә. Алай да, күп очракта нәсел-ыру турында мәгълүматны кешеләр түләп ясата. Бер буын турында мәгълүмат туплау 350 сумнан башлана. Белешмәләрне бер ай эчендә табып бирәчәкләр.

### БАБАЛАР ЯЗМЫШЫН ӨЙРӘНҮ - АЛАРГА ХӨРМӘТ КҮРСӘТҮ

Чыганаклар белән эшләүче Таһир Габдрахманов исә гади кешеләргә дә, олы түрәләргә дә шәҗәрәләр ясый. Әгәр ул Г.Тукай, Ш.Мәрҗани, К.Нәҗми кебек шәхесләрнең нәсел язмаларын кызыклы фактларга баетса, Казандагы 18 нче хастаханәнең баш табибы Рөстәм Бакировка Үтәмешев морза нәселеннән чыкканын ачыкларга ярдәм иткән. Мәскәү, Петербург, Тамбов, Мордовия һәм башка төбәк архивларында документлар өйрәнеп, депутатларыбызга, җитәкчеләргә бабалары турында мәгълүматлар җыя.

Кеше ни өчен үткәне белән кызыксына? Берәүләр аны - мода, икенчеләре PR (пиар) дип саный, өченчеләре бабалар әйтеп калдырылган гамәл, бурыч итеп кабул итә. Үз исемен әйтергә теләмәгән бер танышым әби-бабасы, туган-тумачасы исемен дога кылыр өчен барлый. "Минем бабам кем булганы кардәшләремнән башка берәүне дә кызыксындырмый, ә менә гүргә кергән туганнарым рухына дога кылсам, һәр якка савап булып ирешер иде", - ди танышым. Ислам динендә кеше үлгәч, аңа савап китерә торган өч әйбер телгә алына. Берсе - бирелгән хәер-сәдәка, үзеңнән соң калган гыйлем һәм аның рухына дога кылучы тәүфыйклы нәсел дәвамчылары...

*Миләүшә ЗАКИРОВА*
*Чыганак: www.intertat.ru*

# "Тәварихе Болгария" әсәрен кем язган?

**Татар әдәбияты тарихында кульъязмалар рәвешендә һәм соңрак XIX гасырда басма китаплар рәвешендә халык арасында таралып һәм кызыксынып укыла торган Хисаметдин бине Шәрәфетдин Мөслими дигән язучының "Тәварихе Болгария" дигән әсәренең язмышы үтә катлаулы һәм гыйбрәтле. Авторы турында да төгәл мәгълүматлар юк. Китапның тулы кульъязма нөсхәләренең башында ул үзе турында: "Болгар тирәсендәге Ташбилге авылыннан Хисаметдин бине Шәрәфетдин", ә ахырында: "Шәрәфетдин бине Хисаметдин", дип яза. Шуңа күрә фәндә ул күбрәк Мөслими буларак билгеле. Китапның язылу датасына карата да төрле каршылыклы фикерләр бар. Әсәр текстыннан чыгып караганда аның 1551 - 1584 елларда Ташбилге авылында язылган дигән караш булса да, хәзерге тарих фәнендә әсәрнең язылу вакыты итеп XVIII гасыр ахыры - XIX гасыр башы дигән дата кабул ителгән.**

Бу - Мөслими дигән авторның "Тәварихе Болгария" әсәренең кульъязмалары халыкка барып җиткәнче, татар халкы арасында Таҗетдин бине Ялчыгол дигән авторның "Тарихнамә-и Болгар" исемле шәҗәрә рәвешендәге стильдә язылган әсәре укучылар арасында нык тарала. Кайберәүләр бу китапны, ялгышып, "Тәварихе Болгария" дип атап йөртә. Ләкин Мөслими әсәре үзенең төзелеше һәм язылу максаты ягыннан Т.Ялчыгол әсәреннән нык аерыла.

Шулай ук XIX гасырның соңгы чирегендә, төгәлрәге 1883 елда, Казанда Хөсәен Әмирхан дигән татар тарихчысының да "Тәварихе Болгария" исемле хезмәте дөнья күрә. Әлеге китапның исеме, әлбәттә, Мөслими әсәре тәңгәл килә, ләкин ул эчтәлеге ягыннан анықыннан нык аерыла: анда инде мәгълүматлар реаль, конкрет шәхесләр һәм вакыйгалар белән бәйләнештә бирелә. 2011 елда Казанда галим С.Гыйләҗетдинов тарафыннан XIX гасыр тарихчылары Кадыйр Гали бәкнең "Җәмигыт-тәварих" һәм Хисаметдән Мөслими, Таҗетдән Ялчыгол, Хөсәен Әмирханнарның югарыда телгә алынган "Тәварихе Болгария" исемле әсәрләре бергә тупланып, хәзерге татар теленә якынайтып нәшер ителде. Әлеге китапларны бүгенге татар укучысына җиткерү юлында бик кирәкле эш башкарылды.

Татар әдәбияты тарихчылары Мөслиминең әлеге әсәре белән күптәннән кызыксына, аның турында язалар да. Ләкин бу әсәрнең язылуы, идея ягы әлегәчә җитәрлек ачылмаган килеш кала бирә. Түбәндә газета укучылар хозурына тәкъдим ителүче мәкаләбез борынгы әдәбиятыбызның шушы проблемасын тикшерүгә багышлана.

Мөслиминең "Тәварихе Болгария" әсәре XIX гасырның икенче яртысыннан бирле күчерелеп таралуына әсәрнең дистәләрчә сандагы кульъязмаларының күчермәләре дәлил булып тора. Шулай ук аның XIX гасырның икенче яртысында Казанда нәшер ителгән басмалары да бар. Фәндә бу әсәрнең кайчан язылуы проблемасы әлегәчә махсус тикшерү объекты итеп куелганы юк. Аның язылу вакытын тикшерүчеләр арасында Казан тарихчылары һәм филологлары Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Әхмәров, С.Вахиди, Н.Ф.Калинин һ.б. бар.

"Тәварихе Болгария" әсәрен берсүзсез тарихи чыганак итеп кабул итүчеләр булган кебек, аңа XIX йөздә үк тәнкыйть белән караучы галимнәр дә булган.

Әлеге китапка беренче фәнни тәнкыйть язучы кеше күренекле татар тарихчысы Шиһабетдин Мәрҗани була. Мәрҗани - Мөслими (Хисаметдин бине Шәрәфетдин) әсәрен урта гасыр татар тарихына чыганак буларак хезмәт итүен анализлап, хезмәтне тәнкыйть итә, Мөслими әсәренең нигезле тарихи язма чыганаклар нигезендә язылмаганлыгын күрсәтә.

Татарның күренекле археограф галиме Альберт Фәтхи Ш.Мәрҗанидән соң бу әсәрне чыганак буларак тәнкыйтькә кушылса да, аның татар укучылары арасында популяр булу сәбәбен ачарга тырыша. А.Фәтхи, "Тәварихе Болгария"-нең популяр булуының сере әсәрнең татар халкы тарихына бәйле итеп күрсәтелгән тарихи "риваятьләр", "шәҗәрәләр", "ташбилгеләр" сәхифәләрендә булуын дөрес күрсәтеп, борынгы әдәбият белеменә яңа бер фикер өсти.

Альберт Фәтхи, бу проблема буенча атаклы татар археографы Сәет Вахидиның кульъязмаларына таянып, аның әле фәнни әйләнешкә кермәгән мәгълүматлары барлыгын яза. С.Вахиди язмаларына караганда, Ташбилге авылы янында "Тәварихе Болгария" авторының XIX гасырның беренче яртысында кабер ташы да мәгълүм булган.

"Тәварихе Болгария" әсәренә күренекле тарихчы Ризаэтдин бине Фәхретдин дә бик шөбһә белән караган. Аның иҗатына карата: "Бичараның газиз гомерләре вә кыйммәтле вакытлары урынсызга һәм файдасызга әрәм булган", дигән катгый фикергә килгән.

Алда искә алынган галимнәрнең фикерләре Мөслими иҗатына мөнәсәбәттә, әлеге әсәргә фәнни бәяләү юлында татар әдәбият белемендә ныклы алгарыш барганлыгы күренә.

"Тәварихе Болгария" әсәре белән кызыксынуның яңа этабы 1970 елларда башлана.

Бу өлкәдә өр-яңа фикер тарихчы галим М. Госмановның монографик хезмәтендә күтәрелә.

Ул, үзенә хәтле яшәгән галимнәрнең Мөслиминең "Тәварихе Болгария" әсәре хакындагы фикерләрен, аларның бу мәсьәләгә нинди караштa тору позицияләрен өйрәнә, шулай ук яңа археографик табышларны проблеманы аңлатуда файдалана. Галимнең бу өлкәдәге әһәмиятле фикерләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. "Тәварихе Болгария" әсәре галимнәр игътибарына 1840 еллардан соң гына керә башлый.

2. Әсәрнең табылган кульъязмаларының тик берсе генә, иң борынгысы фәкать 1827 елда күчерелгән дип күрсәтелә.

Моннан тыш, М.Госманов Мөслими әсәренең Таҗетдин Ялчыголовның "Тарихнамә-и Болгар" әсәре белән уртак яклары булуын ача һәм әгәр Мөслими әсәре XVI гасырда язылган булса, Ялчыгол аны үзенең хезмәтендә файдаланыр иде, дигән бик урынлы фикер күтәрә.

Ул, Мөслими әсәренең язылу вакыты итеп 1827 елгы кульъязма күчермәсен документаль итеп карау ягында, ләкин әле тагын да табышлар булу мөмкинлеген искә алып, бәлки XVIII йөз ахыры дип фаразлап торырга тәкъдим итә.

Хисаметдин бине Шәрәфетдин әсәренең чыганаклар базасы һәм аның нинди максаттан чыгып язылу идеясен 1995 елда әдәбият галиме, археограф М.Әхмәтҗанов үзенең бер мәкаләсендә тасвир итә. Автор бу хезмәтендә Хисаметдин бине Шәрәфетдиннең фикерләрен яңа археографик материаллар яктылыгында, гомум Россия империясенең XVIII - XIX гасыр башларындагы тарихи күренешләре яктылыгында, Россиянең дини-милли сәясәте белән бәйләнештә бәян итә.

М.Әхмәтҗановның фикерләре аның тарафыннан 1993 елгы археографик экспедиция вакытында Татарстанның Лениногорск төбәге, Керкәле авылында табылган 1820 елларга караган бер кульъязма белән дә раслана. Ул материал беркадәр өйрәнелеп, аның Мөслими әсәре белән бәйләнеше барлыгы ачыкланып, соңрак ул басылып та чыкты.

Басмада кульъязманың шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни тарафыннан язылу һәм Хисаметдин бине Шәрәфетдин Мөслиминең татар язучысы Таҗетдин Ялчыгол псевдонимы булуы кире кагып булмаслык итеп раслана.

Узган гасыр ахырында Мөслиминең "Тәварихе Болгария" әсәренең, беренче мәртәбә кириллицада әзерләнеп, филология фәннәре кандидаты С. Гыйләҗетдинов тарафыннан басылып чыгуы да бу әсәр белән кызыксынучылар даирәсен киңәйтте.

XXI гасырга кергәч, Мөслими әсәрләре белән кызыксыну Көнбатыш Европа һәм Америка галимнәрендә дә уянды. Алардан Аллен Франк һәм Михаэль Кемпер кебек белгечләрнең язган хезмәтләрендә Мөслими әсәрен анализлауга зур урын бирелә.



Бу авторларның хезмәтләрендә Мөслими әсәре XVIII-XIX гасырлардагы татар тарихы һәм мәдәнияте контекстында карала. Әлеге авторларның Мөслими әсәренә карата үз карашлары бар. Алардан аеруча Михаэль Кемпер "Тәварихе Болгария" китабын бер бөтен әсәр итеп анализлый. Бу - дөрес метод. Татар галимнәренең кайберләре арасында "Тәварихе Болгария"не төрле очраклы язмалардан тупланган дигән фикер әйтүчеләр дә бар.

Ләкин әсәрнең историографиясеннән күренгәнчә, аның 180 еллык гомерендә татар әдәбият тарихында бик зур урын тотуы күренә һәм аның әдәби псевдоним астында язылган Таҗетдин Ялчыгол каләменә нисбәтле булуы ачыла.

**Гүзәлия КӘРИМОВА,**
**Татар энциклопедиясе институты хезмәткәре**

# Җаныбыз тынгылык эзли...

*(Башы газетабызның 2012 елның №1 (118) санында.)*

- Ә инде дога кылып та терелмәсәң?

- Әгәр терелмәсәң яки башка ниндидер максатыңа ирешә алмасаң, "Әлхәмдүлилләһ" дип Раббыңны макта, чөнки Аллаһы Тәгалә белүчерәк. Ул ничек бирә, ничек оештыра - безнең өчен шулай хәерле дип уйларга кирәк. Һәрбер нәрсәдә мәгънә-хикмәт бар.

- Ә хезмәттәшең яки күршең бик начар булуда нинди хикмәт? Әнә безнең урамда торучы ике күрше хатын инде ничә ел талашалар, берсе бигрәк тә әшәке, ай-яй-яй...

- Аллаһ кешеләрне төрлечә сыный бит. Монысы да зур, җитди сынау. Берсе (әшәкесе) күршесенә һөҗүм итә, ди. Ә шул күрше Аллаһыга сыенуны белми - тегесенә җавап бирә. Моның "җене" сөенә, чөнки үзенә беразга гына булса да җитәрлек энергия суырып алды. Тәмам тынычлыгын җуйган теге хатын исә хәлсез калып кереп егыла. Берничә көннән бу хәл кабатлана, чөнки беренчесенә тагын дәрт-энергиясен тулыландырырга кирәк. Ләкин моңа киртә куеп була: яман хатын нәрсә генә дисә дә - дәшмәскә. Зикер кылып, ягъни Аллаһны мактап, күңелеңдә давыл кузгатырга ирек бирмәскә кирәк.

- Ул, бәлки, дәшмәс иде дә, тегесе бит нахакка гаепли, начар сүзләр әйтеп рәнҗетә.

- Бу хакта бер ислам галиме болай дигән: "Әгәр игътибарыңны Аллаһка юнәлдергән чакта кешеләрнең тупаслыгы синең хәтереңне калдырмый һәм кәефеңә тәэсир итми икән, бу йөрәгеңнең олы һәм холкыңның затлы булуын исбатлый". Менә бит кайда хикмәт. Без шайтан кабызып җибәргән учакка "ягулык" өстәп, дәрәҗәбезне генә төшерәбез һәм үзебезгә зыян салабыз.

- Шулай шул, җәнҗалчының түбән дәрәҗәсенә төшеп пычранганчы, аны читләтеп узу һәм җавап бирмәү күпкә яхшырак. Ә шундый начар, хәтта явыз, хәтәр кешеләр янаса, ничек тә булса куркытырга теләсә?

- Моның турында Аллаһы Тәгалә болай ди: "Мин Адәм баласының йөрәгендә ике курку урнаштырмыйм. Әгәр кеше Миннән курыкса, башка беркемнән һәм бернәрсәдән курыкмас. Әгәр Миннән курыкмаса, мәхлуклардан куркуны йөрәгендә урнаштырырмын". Коръәндә мондый мәгънәле аять тә бар: Аллаһның җәзасыннан куркып гөнаһлы гамәлләрдән читләшкән кешегә Аллаһ кыенлыклардан чыгу юлын күрсәтер".

- Ә үлемне ислам дине ничек аңлата? Нишләп шулай бик сагайта һәм куркыта соң ул үлем?

- Бу хакта ислам галимнәре болай диләр...

...Бала ана карынында ярала. Аның шундый искиткеч камил рәвештә формалашуы - үзе бер могҗиза. Ләкин баланың билгеле вакыт үтүгә карында хәрәкәтләнә башлавы, ягъни "терелүе" - безнең акылыбыз аңлап бетерә алмый торган тагын бер сер, тагын бер бөек могҗиза. Бу вакыйга турында халык гади итеп кенә "җан керде" дип әйтә. Кайдан килгән соң ул җан? Кем ясаган аны? Көчсез нәни яралгыга аны кем урнаштырган соң? Хакыйкать бер генә: җан ахирәттән килгән. Аны Аллаһы Тәгалә бар кылган һәм Раббыбыз әмере буенча җанны фәрештәләр балага өреп кертә.

Галимнәр әйтүенә караганда, җан ул - нурдан яратылган җисем. Ул исән, хәрәкәтләнүчән һәм үз асылында яшәүне, гыйлемне, ихтыярны, яхшылык белән начарлык арасында сайлый белү сәләтен һәм адәм баласына хас булырга тиешле башка сыйфатларны туплый. Һәр кешегә ул Раббыбыз Аллаһы Тәгалә бөек хикмәт белән оештырган махсус программа салынган килеш бирелә. Төп максат - һәр җан Аллаһ аңа биргән программаны үтәп, үз вакыты белән ахирәткә, Аллаһы Тәгалә хөкеменә кайтырга тиеш була.

- Бу бер оешма хезмәткәре командировкага җибәрелгән кебек түгелме соң инде? - дип елмаебрак дәеште Илсур.

- Шулай дип тә була, дөрес чагыштырасың. Командировкага киткән кеше үз өстенә бит төрле бурычлар ала һәм үзенә йөкләтелгән вазифаны җиренә җиткереп башкарса, туган якка борчылмыйча һәм сөенеп кайта. Әмма үзенә бирелгән акчаларны тотып бетереп бурычын үтәмәсә, андый хезмәткәргә кайту авыр һәм куркыныч була.

- Ә-ә, менә хәзер мин мәсьәләне бераз аңлыйм бугай: үлем безне шуңа бик сагайта һәм куркыта, чөнки...

- ...Чөнки үлем ул - җан белән тәннең аерылуы һәм җанның үз "ватанына" - ахирәткә кайтып китүе. Ахирәттә исә бөтен "программа" буенча Аллаһы Тәгалә каршында җавап тотасы була.

- Менә нигә безнең җаннарыбыз тыныч түгел икән, - диде Илсур уйчан гына. - Ахирәткә, мәңгелеккә күчкәч, ничек җавап бирербез дип кайгыралар алар, димәк...

- Нәкъ шулай. Безгә бирелгән сәламәтлек, акыл, нәрсәдер эшләргә мөмкинлек бу дөньяда яшәр өчен генә түгел, ахирәткә әзерләнер өчен дә бирелгән нигъмәт ул.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Алтынның нанокисәкчекләре рак авыруын дәвалый!

## (Мисыр галимнәренең ачышы)



**Мисырда баручы сәяси процесслар әлегә илнең фән өлкәсенә начар тәэсир ясап өлгермәгән, ахрысы. Моны Мисыр галимнәренең соңгы ачышы да дәлилли. www.itar-tass.com сайты биргән мәгълүматларга караганда, яман шешне дәвалауда алтын куллану уңай нәтиҗәләргә китергән.**

"Рак күзәнәкләренең таралмавына каршы тору өчен алтынның нанокисәкчекләрен куллану нәтиҗәлелеген клиник тәҗрибәләр дә раслады", - дип белдерде Каһирә шәһәре фәнни тикшеренүләренең Милли үзәгендә үткән матбугат очрашуында табиб Мостафа әс-Сәет.

Лазер ярдәмендә авыртуның "үзәге"нә китертелгән алтынның нанокисәкчекләре, шешнең кан тамырлары зәгыйфьләнүе нәтиҗәсендә, ракны туктата. Галим билгеләп үткәнчә, бу ысул белән бары тик авыру күзәнәкләргә генә йогынты ясала, моның сәламәт күзәнәкләр өчен бернинди дә зыяны юк.

Хәзерге вакытта хайваннарда клиник сынаулар үткәрелә. Өстәмә начар тәэсирләрнең булмавы тулысынча дәлилләнгәннән соң, сынаулар авыру кешеләр белән башкарылачак. Доктор Мостафа әс-Сәет фикеренчә, нанокисәкчекләрне куллану нәтиҗәле булган очракта, ул бавыр, бөер, талак (селезёнка) рагын дәвалауда үзенең хәлиткеч ролен күрсәтә алачак.

***ФОТОДА:*** алтынның нанокисәкчекләре рак күзәнәкләренең таралуына юл куймый.

**www.islam.ru сайты хәбәрләрен файдаланып,**
**КФУдагы Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеге студенткасы Ландыш ҖИҺАНШИНА**

# Яңа чишмәдә бәйге узды

**Бүгенге көндә Яңа чишмә районындагы 11 мәчетнең җидесендә балаларга дини дәресләр бирелә.**

8 гыйнвар көнне Акбүре мәчетендә балалар өчен үткәрелгән бәйгедә һәр мәчеттән бишәр бала катнашты. Балалар үзләрен төрле уен-конкурсларда сынады. Иң беренче сынау - балаларның белемнәрен тест ярдәмендә ачыклау булды. Конкурс шулай ук азан әйтү, Коръән сүрәләре һәм догалар уку кебек этапларга да бүлеп үткәрелде. I, II, III урыннар алучыларга кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Гомумән, бер генә бала да бүләксез калмады.

Очрашу чәй эчү белән тәмамланды. Акбүре авылы имамы Хәмзә хәзрәт Шәрифуллин һәм авыл Советы башлыгы Җәүдәт Җәләлетдинов килгән кунакларга үз рәхмәтен җиткерде.

Бәйгене оештыру-үткәрүдә авыл җирлеге халкы, Акбүре мәчете имамы гаиләсе, хуҗалык җитәкчеләре зур тырышлык куйды.

Бәйгедә аеруча зур активлыкны Казандагы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә укучы студентлар - Гәрәева Гөлүсә һәм Габдрафикова Миләүшә күрсәтте.

42 бала катнашкан бәйгенең чыгымнарын мөхтәсибәт үз өстенә алды.

***Яңа чишмә мөхтәсибәтенең дәгъват кылу һәм мәгълүмат бирү бүлеге***



# Мәрхәмәтле булыйк!



Мөхетдинов Самат Миңзакир улы - безнең ярдәмгә мохтаҗ, ул физик мөмкинлекләре чикләнгән 48 яшьлек ир-ат. Аллаһы Тәгалә аңа бу дөньяда зур сынау бирә: 22 яшендә җәрәхәт алганнан соң, Самат үз гомерен коляскада кичерергә дучар була. Аянычлы вакыйгага кадәр ул, югары медицина белеме алып, балалар клиникасында массаж һәм физкультура буенча инструктор булып эшли, кешеләрне дәвалый. Кызганыч, хәзер файдалы эшен дәвам иттерә алмый. Хәзерге көндә Самат ялгыз яши, аның гаиләсе юк. Язмыш сынауларына карамастан, ул искиткеч оптимист, күтәренке күңелле кеше, аның белән аралашу - үзенә бер бәйрәм, җан рәхәте. Самат һәркөн үзе өстендә эшли, актив тормыш итәргә тырыша. Хәтта читтән торып югары юридик белем дә алган. Янында якын кешеләре булмаганга күрә, Самат аралашу һәм урамга чыгып һава сулау өчен мәрхәмәтле кешеләр эзли. Аның авыруын дәвалау ысулы да билгеле булды: аңа Германиядә кыйммәтле операция ясату өчен бер миллион сум акча кирәк.

Мөселман кардәшләребез! Саматка хәлебездән килгәнчә ярдәм итик! Яхшылык җирдә ятмый. Изге эшләрегез өчен Аллаһы Тәгалә Сезне зурлар!

Саматка ярдәм итәргә теләүчеләр "Зәкят" хәйрия фондына мөрәҗәгать итә ала:

***Адрес: 420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.***

***Телефон: +7 (843) 236-46-32, 264-60-08; факс: +7 (843) 236-37-62.***

***Электрон почта: fondzakyat@yandex.ru.***

***Сайт: www.закят.рф.***

***Шулай ук акчаларны түбәндә китерелгән исәп-хисап счётына да күчерергә мөмкин:***

***ИНН 1655068682***

***ОГРН 1091600003153***

***р/с 40703810400020000071 в ОАО "Ак Барс" Банк в г.Казани***

***к/с 30101810000000000805***

***БИК 049205805***

***Назначение платежа: благотворительная помощь Мухутдинову С.М.***

# Җаныбыз тынгылык эзли...

***(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)***

- Ә күп кешеләр дөнья өчен генә яши...

- ...Һәм ахирәт тормышына ышанмаганга, аны белмәгәнгә күрә бөтен өметен дөнья тормышына баглый, дөнья малы табам дип тырыша: шул мал артса, сөенә, ә югалтса - бик кайгыра. Ләкин кеше нинди генә матди "юатулар" уйлап тапмасын, аның күңеле канәгатьләнә алмый, чөнки, әйткәнемчә, җанның бу дөньяга килүенең төп максаты байлык туплау түгел, ә тән белән берлектә аларны юктан бар кылган Яратучыга гыйбадәт итү. Аллаһ белән кеше арасы төзек, дөрес булмаганга гына күңел сыкрый, борчыла.

Шушы сүзләр Илсур йөрәгенә үтеп керсә дә, аның күңел төбендә бер шикләнү "корты" кымырдап, үзенең үҗәт авазы белән хакыйкатьне кире кагып карады:

- Белмим инде... гел намаз укып, мәчеткә йөреп кенә тормыш итеп булмый бит...

- Ә кем әйтә көне-төне намаз гына укы дип? Көнетөне дөнья эшен генә эшлә дип әйтүче дә юк. Һәр нәрсәнең - эшнең дә, ялның да, намазның да - үз вакыты. Кыска гына намазга караганда дөньяви эшләребезгә шактый күбрәк вакыт бирелә бит әле. Бу беренчедән. Ә икенчедән, сөйләшүебез башында үзең әйттең: кеше зәгыйфь һәм мохтаҗ. Кичтән моны эшлим, тегене башкарам, иртәгә таулар әйләндерәм дип планлаштырып куясың, ә иртәгесен, авырып китеп, ятагыңнан да тора алмыйсың. Шулай булуы мөмкинме? Бик мөмкин... Өченчедән, иман-ышаныч дөнья эшләрен башкаруда да зур терәк-ярдәмче: бисмиллаһны әйтеп, Аллаһыга тәвәккәлләп эшләсәң, нәтиҗәсе ничек булса да, күңел барыбер тыныч кала, чөнки Раббыбыздан хәерлесен сорадык. Ә Аллаһы Тәгалә теләгәнчә, Ул кушканча яшәгәнгә күрә, кешенең җаны ахирәткә ничек кайтып китәрмен дип тә борчылмый.

Күңел тыныч кала... Моны ишетүгә Илсурның күз аллары кинәт ачылып киткәндәй булып, йөрәгендә ниндидер изге җылылык белән өртелгән очкын кабынды. Шушы очкын Илсур кальбен йомшак кына итеп яктыртты, күңелен исә аңлаешсыз шатлык, өмет биләп алды. Һәм ни хикмәт - әлеге яктылык сүрелми, кимеми! Борчулы йөрәктә пәйда булган ышаныч Илсурны үз тормышына, бу дөньяга - бар Галәмгә! - икенче төрле каратты.

- Әйе! Бу Галәмнең Яратучысы булуына мин ышанам! - диде аңа йөрәге. - Ул - яшәүнең һәм үлемнең Хуҗасы, Адәм балаларын сәламәтлек, ризык, һава белән нигъмәтләндерүче, безне бу дөньяда сынап, ахирәттә каршы алачак бөек Раббыбыз... Аның бөеклеге куе урманнарда һәм иксез-чиксез тирән дәрьяда, чәчәк тулы матур болыннарда, төнге күкнең серлелегендә... Шушы мәхлукатлар бер максатсыз һәм мәгънәсез яратылмаган һәм алар үзләренә йөкләтелгән вазифаларны төгәл башкара. Кешеләр яшәешендә дә зур, бөек Максат бар. Бөек Максат...

Гыйлем һәм хакыйкать юлларында әле шактый күп адым ясарга туры киләчәк Илсурга. Ләкин бу тормышта аңа бирелгән күп нигъмәтләр Аллаһының бик зур бүләге булуын ул инде хәзер аңлый һәм ихластан шөкер кыла. Көн саен якынлаша торган ахирәт тормышы турында да Илсур хәзер уйламыйча яшәмәс. Ахирәткә кертүче "ишек" янына килеп җиткәч тә, ул шул ишекне курыкмыйча ачар. Мәңгелеккә таба илтә торган тормыш юлында проблемалар, авырлыклар булмый калмас. Әмма Иман, Аллаһыга ныклы ышаныч белән яшәгәндә, хәвеф-хәтәр һәм кыенлык төн кебек үтәчәк. Чөнки иманлылар шикләнмичә ышана: ул "төн" узар һәм, һичшиксез, аны игелекле, сөенечле, яп-якты "көн" алыштырачак. Сөенечле, Якты Көн...

***Ришат КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе мөдире***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 14.01.2012 | 7:35 | 09:05 | 13:02 | 15:27 | 16:40 | 18:10 |
| *Якшәмбе* | 15.01.2012 | 7:34 | 09:04 | 13:02 | 15:28 | 16:41 | 18:11 |
| *Дүшәмбе* | 16.01.2012 | 7:33 | 09:03 | 13:02 | 15:29 | 16:43 | 18:13 |
| *Сишәмбе* | 17.01.2012 | 7:32 | 09:02 | 13:02 | 15:31 | 16:45 | 18:15 |
| *Чәршәмбе* | 18.01.2012 | 7:31 | 09:01 | 13:02 | 15:32 | 16:47 | 18:17 |
| *Пәнҗешәмбе* | 19.01.2012 | 7:30 | 09:00 | 13:02 | 15:33 | 16:49 | 18:19 |
| *Җомга* | 20.01.2012 | 7:28 | 08:58 | 13:02 | 15:35 | 16:51 | 18:21 |
| *Шимбә* | 21.01.2012 | 7:27 | 08:57 | 13:02 | 15:36 | 16:53 | 18:23 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №2 (119) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-522.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 12 гыйнвар көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**